

Совет гаскәрләренен Афганистаннан чыгарылуына 30 ел тулу унаеннан Мордовиядә торле чаралар үткәрелде. Истәлекле дата кин билгеләнде.
Тагы бер мисал. 2019нчы елнын 13 февралендә Ләмберә районы Большая Елховка авылында Афганистаннан Совет гаскәрләренен чыгарылуына утыз ел тулу унаеннан митинг үткән. Чарада социаль мәсьәләләр буенча район главасы урынбасары Р.Х.Салимова, Большеелховка авылы главасы Ю.С.Зеленцов, «Боевое братство» ижтимагый оешманын район бүлеге рәисе М.Н.Салеев, район хәрби бүлек житәкчесе ярдәмчесе Р.Х.Севкаев, «Большеелховская СОШ» директоры А.М.Афроськин, Ләмберә районы ветераннары Советы әгъзасы Р.Д.Кряков, Б.Елховка авылы ветераннары Советы житәкчесе Н.И.Литюшкин һәм Ләмберә районы сугышчы-интернацио-налистлары: Марат Хайдар улы Рагузин, Наиль Касим улы Вагапов, Рәстәм Раис улы Серебряков, Камиль Абдрашит улы Заликов, Олег Иванович Белоглазов, Игорь Александрович Сухов һәм башкалар катнашында үткән.



Афганистанда Ләмберә районыннан 79 кеше хезмәт иткән. Аларнын күбесе күрсәткән батырлыклары очен орден һәм медальләр белән бүләкләнгәннәр.
Шул ук конне Ләмберә админи-страциясенен зур залында шул ук теманы яктырткан тантаналы чара үткән. Приказ үтәп, батырлыклары очен «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнгән татар милләтле Ләмберә афганчысы - Марс Нәсрулла улы Ахметов һәм Черемиштән Ринат Шамиль улы Альмяшев, «Батырлык очен» («За отвагу») медале алган Большая Елховкадан Юнир Ильяс улы Мамеев һәм Аксеннан Рафаэль Няим улы Алимов, Звездный авылыннан Марат Хайдар улы Рагузин һәм башка хормәтле сугыш ветераннары чарада булган. Бу тантаналы кичәдә республика афганчылары авыр хәрби хезмәт елларын, сугышчан дусларын искә алдылар. Ветераннар үзләре белән булган вакыйгалар турында сойләде, балаларнын сорауларына жавап бирде. Мондый

хормәтләvләр vсеп килvче яшь буынга патриотик тәрбия бирv очен ин унай булуын әйттеләр.